ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮНЬ * 2020 * КАЗАН

6



Сергей АНДРИАНОВ

2 нче битне кара.



Йөз еллык юбилей – уен эш түгел. Бигрәк тә Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгы. 1920 елның 27 маенда, ул вакытка инде Ленин булырга өлгергән элекке Казан студенты безнең республиканы булдыру турындагы декретка кул куйган. Татарлар яңадан, дүрт гасыр узгач, тулысынча үзәккә буйсынучы булса да, дәүләт статусы алды. Шуңа күрә Казанның үзәк мәйданында әлегә кадәр Владимир Ильичка һәйкәл тора...

Өч елдан соң, 1923 елда республикада тагын бер әһәмиятле вакыйга булды. Казанда, башка басмалар белән беррәттән, республиканың елъязмачысына әверелгән "Чаян" журналы чыгарыла башлады. Яңа властьның урнашуы, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү, Бөек җиңү, сугыштан соң илне торгызу, зур нефть, КамАЗ, алга киткән социализм, үзгәртеп кору, суверенитет, Казанның 1000 еллыгы – бу вакыйгалар барысы да журнал битләрендә урын алды.

Сатира журналында мондый җитди мәсьәләләрне яктырту җиңел булмагандыр, әлбәттә. Мәсәлән, чаянчы өчен совет матбугаты тарафыннан уйлап чыгарылган, оксюморон дип аталган уңай фельетон язу иң катлаулы эш иде... Әмма журналистлар сер бирмәде – "кирәкле" материалларны юмор белән, укучы ышанырлык итеп яздылар.

«Чаян» республика белән бергә яңа тарихның Лениннан Путинга кадәр иң катлаулы, бормалы юлларын үтте. Төрле елларда буржуйлар белән кулакларның, халык дошманнары һәм космополит, капиталист, империалист һәм колонизаторларның тетмәсен тетте. Дин һәм хорафатлар, милләтчелек һәм "искелеккә тартучы" көрәнешләргә каршы көрәште. Шул ук вакытта "Чаян", гади кешенең мәнфәгатьләрен яклап, җансыз бюрократларны, карьерист һәм ришвәтчеләрне ут астында тотты. Шуңа күрә дә ул чакларда еш яңгырый торган "Менә "Чаян"га язармын әле!" сүзләре көнкүреш тормышка сеңеп керде.

«Чаян» – сатирик кына түгел, ә тарихи журнал да, аның буенча республикабызның тарихын өйрәнергә була. Шуңа күрә Татарстанның юбилее безнең юбилей да. Ә журналыбызның өч елдан соң булачак юбилее бөтен республикага яңгырар дип ышанабыз...

Туган көнең белән, Татарстан!





ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле редакция! Согуд гарәпләре һәм коронавирус бер ай эчендә безгә 20 ел буе вәгъдә ителеп килгән нәрсәне эшләде – нефтьтән бәйсез итте. Аңа ихтыяҗ күпкә кимеде, бәясе төште, ил бюджеты саекты... Бу катлаулы вакытта туйдырып торучы нефть акчасыннан башка ничек яшәрбез икән?

Л. КӘНӘФИЕВ

Әлмәт

Укучыбызның соравы Шомбай агада зур кызыксыну уятты. **– Бездә бит «икенче нефть» тә бар әле. Бу – соңгы вакытта күпләп җыела торган штрафлар, –** диде аксакалыбыз. **– Нефть туйдыра алмаса, штрафлар туйдырыр әле...**



ШИГЫРЬГӘ СЫЛТАП

Талия ГЫЙМАЛТДИНОВА

Урта кул житәкчеләргә
Калды безнең төбәкләр.
Алары да үлеп бетсә
Безне кемнәр житәкләр?..

Сайлауларның нәтиҗәсе
Алдан билгеле безгә.
"Бердәмлеләр" сайланмаса, –
диделәр, – көн юк сезгә!"

Уку-укыту эшләре
Яхшы куелган бездә.
Дөнья һаман шулай барса –
Ликбез ачарлар көзгә.


Пай җирләрен сатып ала
Баераклар, көчлеләр.
Чокыр-чакырларга калгач,
Ни эшләр хәерчеләр?

Кыз шәһәрдән кияү эзли,
Авылларда ише юк.
Гармуннарда уйнаучының
Авызын ачса теше юк.
Теш куйдырыр иде дә бит.
Куя белгән кеше юк.

Авылларда муллалар юк
Үгәргә дин йоласын.

Бабайлары гүр иясе,
Әби-чәби – сакалсыз...
Мәчет манаралары,
Манара аралары.

Әйттерәләр, типтерәләр
Замана балалары.



Максим СМАГИН

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Совет заманында интернационализм "инородецлар"га кәчләп тагылган иде, хәзер исә безгә "Бөек Россия" фикерен тукып торалар. Россия "бөек"легенең алтмыш проценты золымнан (насилие) торганын нишләптер оныталар...

Алмаз Хәмзин: Әйе, дисәм, икебезнең дә "кирәк"не бирәләр инде, *кәнишне...*

Р. Н.: Туган телне стенага терәделәр, инде залп бирергә дә ерак түгел, ахрысы?..

А. Х.: Ишетмәсәң дә, синең сиземләвең көчле!

Р. Н.: Картада бармак башы хәтле Катар дәүләтенең ике милли университеты бар. Илне илле ел буена нефтькә коендырган, Россиядәге күп төбәкләргә донор булган Татарстанга милли университет ачарга рөхсәт юк.

А. Х.: Безгә "катарга" гына кала инде.

Р. Н.: Путин, оборона министры Шойгу белән Тувада гөмбә генә җыймады, "армия минем яклы" дигән очколар да җыйды. Эшләпәләре белән үзләре дә горездә гөмбәсенә охшаганнар иде, хәтерлисеңме?

А. Х.: Рәсәй ике гөмбәгә арткан булып чыга түгелме соң?..

Р. Н.: Мондый очракта безгә алар белән чәй артында сөйләшеп утырырга була.

А. Х.: Димәк, Рәсәй дүрт гөмбәгә артачак!

Р. Н.: Елмаер өчен дә берәр сәбәп кирәк.

А. Х.: Менә бит "гөмбә" темасы белән елмайтып алдың әле.

Р. Н.: Кеше кайчан матур була – елмайганда! Димәк, "Чаян" журналын укып баручылар матур кешеләр чутына керә...

А. Х.: Син әйтәсеңме инде аны, минме?!.

Р. Н.: Акча төртеп яки "блат" белән җәннәткә кереп булмый.

А. Х.: Була. Депутатлык шул ук җәннәт бит инде ул.

Р. Н.: Бүгенге тормыш шикәр түгел, гәрчискә күбрәк охшаган, әйеме?

А. Х.: Безнең тормышның ниндилеген билгели торган сүз әле уйлап табылмаган.

Р. Н.: Алмаз туган! Син шигырьләр язасың, көйләр чыгарасың, баянда уйныйсың һәм үзең җырлыйсың. Сине "ноталарны буйсындыручы" да дисәк, дөрес булырмы...

А. Х.: Язучылар арасында шундый берәүнең булуы кирәктер бит инде?..

Р. Н.: Оптимист булу – үзе ярты сәламәтлек.

А. Х.: Оптимист булу – мондый бозык җәмгыятьтәге "Чаян"да эшли алу батырлыгына тиң!

Ышаныгыз миңа, кешеләр!

Күптән түгел безнең ишегебезне дә бәхет шакыды – атна буе бер генә начар нәрсә дә булмады! Яхшысы да булмады, әлбәттә, тик анысына ияләнелгән инде... Ә монда җиде көн берни дә юк! Бензин бәясе күкләргә очып менмәде, рубль «ишелмәде», бернәрсә дә янмады һәм җимерелмәде, бер губернаторны да утыртмадылар... Аның каравы, ялган газ, водоканал, собес әһелләре һәм башка ялганчылар җанланды. Фатирлар буйлап чабып йөриләр – башлары томанланган кешеләр акчалары белән җиңел хушлашырлар дип өметләнәләр. Һәм чынлап та кайберәүләр хушлаша. Бер бабай әнә иртән *7 мең сумга «газ сигнализациясе» куйдырткан*, төштән соң 65 меңгә су фильтры, ә кич белән, туганнарыннан үзенең белем һәм акыл дәрәҗәсе турында тискәре бәя алгач, моңсуланып полициягә юл тоткан...

Әле дә исемдә, берничә ел элек шушы ук егетләр (алар ул чакта яшьрәк иделәр әле) юа торган тузан суырткычлар белән йөргәннәр иде. Тылсымлы машинаны эшләтеп күрсәтеп, һаләк булган тузан бетләрен санап, киң елмаю белән суырту җайланмасын 100 мең сумга калдырып китәләр иде. Әйтергә кирәк, минем хатын да моңа капты. Өстәвенә әле, кибеттә 25 мең сум тора дип, 4 меңгә пычаклар җыелмасы тәкъдим иткәннәр. Соңыннан пычакларның кисми, ә тузан суырткычның пычагым да суыртмый икәнлеге ачыкланды.

Әйткәч әйтим инде, берзаман үзем дә 2 меңгә планшет сатып алдым. Кәеф күтәренке иде, кунактан кайтып килә идем. Тасма телле сатучы озак итеп хезмәт хакы түләмәүче начар нәчәлник турында сөйләде. Хәзер бу планшет ахмаклыгымның һәйкәле булып тузан җыеп ята. Аның каравы, «метро казучылар» тәкъдим иткән бер генә борынгы тәңкәне дә алмадым. Һәм әллә «Шәһәр сәламәтлеге», әллә «Таза шәһәр» тәкъдим иткән бавырны түләүсез тикшерүдән баш тарттым. Ә күрше хатын, ышанып, барган. Үксеп кайтып керде – берничә көн яшисе калган икән бичараның. «Шлаклар белән тулып, киеренке хәлгә килгән бавыр» дигән диагноз алсаң, үксемәссең синә! Әле ярый, кирәкле дарулар УЗИ ясаган кабинетта ук сатылган. 120 мең сумга гомерен коткарганнар, дарулары да барысы да табигый. Мин аңа агулы гөмбаләрнең дә табигый булуы турында исенә төшереп тормадым. Аның бит әле тикшерелмәгән, түләүсез эшләп яткан эчке органнары күпме! Һәм заманында Чумакның «корылган» суларыннан башын югалтып йөргән югары белемле кешегә нәрсә аңлатып булсын?


Шунысы кызык, әле күптән түгел генә түләү өчен минем, имештер, машинада кеше бәрдергән улымны җибәрергә тәкъдим ясаган кешеләр кая китте икән? Бүген банк исеменнән карта мәгълүматларымны һәм ПИН-кодны сораучылар шулар түгелме икән? Әллә алар хәзер төзек пластик тәрәзәләрне рәтләү белән шөгыльләнәме икән? «Исәнмесез... *Бары тик бүген генә... Шәһәр программасы буенча түләүсез ре*монт... Безнең белгеч очраклы рәвештә иртәрәк бушады һәм ул сезнең тәрәзә астында тора... Әгәр дә ул хәзер үк механизмнарны майлап чыкмаса, кышын тәрәзәләрегез чатнаячак һәм ул чакта ремот кыйбаткарак төшәчәк... Без шулай ук түләүсез юридик хезмәт күрсәтәбез...»

Хәзер нәрсә, кешеләргә бөтенләй ышанмаскамыни инде? Юк, ышанынга кирәк. Ләкин барысына да түгел. Миңа ышанырга ярый. Дүшәмбедән бизнес ачып җибәрәм – фатир стеналарын, идәннәрен һәм түшәмнәрен радиациягә тикшерү, ә кирәк булса – дезактивация ясап эшкәрту. Мәсәлән, бер йөз яшьлек әби яшәп ята ди, ә фатирының радиациягә чумып ятканын белми дә. Мин инде иске аккумулятор да әзерләп куйдым, аны селкетеп алсаң, приборның теле коточкыч саннар күрсәтә. Акыллы сүзләр дә өйрәндем – «бүлмәгездә толуол концентрациясе сәгатенә 2,57 микрозиверт, бу – нормаль, ә менә торий кисәкчәләренең күләме 5 тапкырга артып киткән». Тикшерү – 3 мең, дезактивация – 10. Акча бик кирәк, әдәби эшчәнлек табыш китерми. Монда инде иске тузан суырткыч та бик ярый, йөзеңә противогаз киеп куярга да була. Суырткыч щёткасын стена буенча йөртеп чыгам, әбигә прибор телен күрсәтәм, пичәтле квитанция тотырып бирәм, противогазны салам, акча алам һәм – вәссәлам! Акча янчыкларыгызны әзерләгез һәм ишекләрегезне ачыгыз.

Ләкин бер кисәтү! Ишекне миңа гына ачарга, чөнки башкалар – мошенниклар! Әгәр аларга акча бирсәгез, сезнең баш миенә УЗИ ясарга кирәк. «Баш миегезне эшләтеп җибәрегез» программасы буенча...

Илья КРИШТУЛ







- Доктор, миңа җитмеш яшь ә мин әле кызлар артыннан чабам.
- Бик шәп!
- Әйе, ләкин нигә чапканымны хәтерли алмыйм!

Медузаның баш миеннән башка 650 миллион ел яшәү факты күп кешеләрдә өмет уята.

Белгечләр әйтүенчә, һәрбер рәсәйле өендә 80 нән алып 150 мең сумга кадәр акча тота. Беләсе иде, минем акчалар кайда икән?

Өенә ир хатыны башка ир белән түшәктә яткан чакта кайтып керә.
- Кем бу? – дип сорый ул, ярсыган, калтыранган хәлдә.
- Гафу ит, кадерлем, – дип җавап бирә хатыны, – мин белмим, без әле генә таныштык.

Кыз белән егет бакча эскәмиясендә утыра.
- Әгәр дә син хәзер мине үпсәң, мәңгегә синеке булачакмын, – ди кыз.
- Мәңгегә? – дип сикереп тора егет. – Кисәтүең өчен рәхмәт!

Өйдә утырып, балалар нәрсәгә өйрәнер – белмим, әмма ата-аналарның белем дәрәҗәсе, һичшиксез, үсәчәк!

Хатын-кыз – кәрәзле телефон кебек: йә элемтә начар, йә буш түгел, йә акчасы беткән...

Антисептик алам дип чыккан идем, коньяк белән кайтып кердем. Бәясе бер үк ич!

- Син миннән хәлләрең ничек дип сорамыйсың?
- Ярый, хәлләрең ничек?
- Әй, сорама да инде!



Абау!

ОСТА КУЛЛАР

Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Артур Әбделҗанов ата-аналарга балалар мәйданчыкларын үз куллары белән бизәргә тәкъдим итә. Үзенең Инстаграмында, сокланып, иске покрышкалардан ясалган аккош, иске шешәләрдән кояш, пластик стаканнардан ясалган колаклы аю һәм башка буялган чүп-чар күрсәтә. Абунәчеләре закончыга мондый максат өчен ташландык материаллар куллануның законсыз булуын, һәм аның өчен зур гына штраф каралу турында исенә төшергәннәр.

ПОНИ САТКАННАР

Казандагы Республика яшүсмерләр спорт мәктәбе хезмәткәрләренә каршы җинаять эше кузгатылган. Тикшерү органнары аларны мәктәп милке булып саналган понины сатуда гаепли. Бу гамәлне кылыр алдыннан җәнлекне үлгән дип теркәгәннәр һәм оешма балансыннан төшергәннәр. Сау сәламәт пони өчен 10 мең сум алынган, ә мәктәпкә китерелгән зыян 60 мең сум тәшкил иткән.

БИШ ЙӨЗ КАБЕРДӘН ТАБЫШ

Сугыш ветераннарына һәйкәлләр өчен каралган Оборона министрлыгы акчасын урлау максаты белән, мошенниклар чын «үлемсез полк» уйлап чыгарганнар. Махсус органнар хезмәткәрләре хәрби комиссариат базаларында ярты мең чамасы дөньяда булмаган «сугыш ветераннарын» тапканнар. Аларга ясалган һәйкәлләрнең һәрберсе өчен компенсация түләнгән, ә акчаны ике шикле җирләү агентлыгы алган. Бу схема ел ярым дәвамында эшләп килгән һәм оештыручыларга 16 миллион сум табыш китергән.

БӘХӘСЛЕ ҖИР

Татарстандагы Җәлил бистәсендә яшәүче күп балалы гаиләгә йорт төзү өчен җир бүлеп биргәннәр. Бәхетле хуҗалар аны үзләштерә башларга дип баргач, бу җирдә төзергә ярамаганы ачыкланган. Территория Бикасаз югары басымлы насос станциясенең саклау зонасында урнашкан икән. Ләкин җирле хакимият башка мәйдан бирүдән баш тарткан. Бу бәхәсне хәзер прокуратура хәл итәргә җыена.





Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Эльвира ДЫШАЕВА



Ринат АБЗАЛОВ

БОРЫЛЫП ТА КАРАМАМ

Самоизоляцияләре
Гел булмас, бетәр әле;
Өйдә бикләнеп ятулар
Берзаман үтәр әле.

Һәм ул көнне маска кими
Чыгармын мин урамга –
Йөрермен әлсерәгәнче,
Карамый-җил буранга.

Социаль дистанцияне
Онытырмын мәңгегә,
Һәм үбәрмен хатыннарны,
Карамыйча яшенә.

Барча парк-бульварларны
Көне буе буйлармын.
Очаган ир-егетләрне
Сыра белән сыйлармын.

Җырлап-биеп ду килермен,
Һәм кагармын барабан.
Ә тилмерткән өй ягына
Борылып та карамам.

Дамир МОРТАЗИН

Серле тойгы

Смартфон чыелдап куйды һәм экранда таныш булмаган телефон номерыннан СМС пайда булды. «Сезнең белән танышырга телим. Сез миңа бик ошыйсыз». Ә янында йөрәк сурәте.

Мин аптырашта калдым. Сайлау алды агитаторларыннан башка, минем белән күптәннән беркемнең дә кызыксынганы юк иде. «Усал шаяртуга охшаган... – дип уйлап куйдым. – Шулай да, кем белә бит... Нигә җавап биреп карамаска?»

Бармагым белән төймәләргә төртә башладым. «Сез кем? Минем номерны каян беләсез?»

Җавап шунда ук килеп җитте. «Мин сезне күптәннән яратып йөрим. Номерыгызны ничек таптыммы? Сөйгән йөрәк әллә нәрсәләргә сәләтле! Ышаныгыз, чын күңелдән сөйлим...»

«Нигә әле мин сезгә ышанырга тиеш?» – дим.

«Теләмәсәгез, бер сүзем юк! Сезне кыю ир дип уйлаган идем, ә сез...» – дигән үпкәле җавап килде, ә янында – кара роза.

Икенче көнем нindидер сәер дулкынлануда узды. Бәлки, аның тойгылары чынлап та җитдидер? Нәрсә, минем кемгәдер ошавым мөмкин түгелмени? Әйе, бераз корсагым бар, чәч тә сыекланып килә, күз төпләрем салынып тора... Мәхәббәт кыяфәткә карап тормый бит ул!..

Түзмәдем һәм гашыйк йөрәккә СМС җибәрдем: «Димәк, мин сезгә ничек ышанырга тиеш инде?»

«Әйдәгез, очрашыйк – үзегез аңларсыз...» – дип җавап бирде ул.

Тагын бер көнемне газаплы уйлар диңгезендә уздырдым. Очрашыргамы, юкмы? Бәлки, кемдер шаяртырга гына телидер? Ә бу чынлап та шашкын тойгы булса? Нәрсә, мин ир кеше түгелмени? Һәм очрашырга карар кылдым...

«Кайда очрашабыз? Мин сезне ничек танырмын?»

«Иртәгә биштә «Кабартма» кафесында көтегез. Мин сезне үзем табармын...»

Нәкъ сәгать биштә, як-ягыма каранып, мин «Кабартма»да утыра идем. Ярты сәгать үтте, ләкин серле чәчәгем күренмәде.

«Сез кайда?» – дип җыйдым мин оеган бармакларым белән.

«Каршыдагы супермаркетта. Сезнең хатыныгыз белән. Ул миңа шампанский сатып ала!»

Кафедан уктай атылып чыктым, ләкин мине хәләлемнең тавышы туктатты.

– Тукта! Кил әле монда!

Башымны иеп, хатыныма таба атладым.

– Синең аркада бер кап шампанский югалттым, – дип яңгырады кырыс тавыш. – Бергә эшләүче хатынга оттырдым... Синең тугрылыгыңда һич шикләнми идем... Ә ул миңа бәхәсләшергә тәкъдим итте...

– Мин... ул... теге, ни... – дип мыгырдандым.

– Яп авызыңны, сөйрәлчек! Өйгә – марш. Күрмәгәнеңне күрсәтермен әле мин сиңа!

Валерий АНТОНОВ

БӨТЕН НӘРСӘНЕ – ЦИФРАГА!

Тышта нинди гасыр, хөрмәтле әфәнделәр? Интернет гасыры, цифралы икътисад һәм нанотехнологияләр һәм виртуаль тормыш гасыры! Шуңа күрә замананың киң адымнарыннан артта калмыйбыз. Тау-тау макулатура җыеп, кәгазьләрне өстәлдән – архивка, һәм архивтан кире өстәлгә күчереп утыра торган вакытлар үтте...

Мине дөрес аңлавыгызны үтенәм – искелек богауларыннан ычкынырга кирәк, алайса искелек сазлыгында батып үләбез. Бөтен нәрсәне – цифрага! Барыбыз да – компьютер янына! Җаваплылыкны үз өстебезгә алыр өчен һәрберебез дә элемтәдә булырга тиеш. Бары тик электрон форматта гына эшлибез. Файл юк икән – эш юк. Эш урынында Интернет юк икән – димәк, эш урыны да юк. Кем булдыра ала – өендә эшли! Бернинди ял көннәре һәм бәйрәмнәр юк! Эшне тикшерү – скайп буенча. Киңәшмәләр ZOOMда. Документлар кабул итү электрон почта буенча. Теркәү – электрон имза ярдәмендә. Отчётлар цифрада гына. Күрсәткечләрне компьютерда гына төзәтәбез. Карарларны фотошопта эшкәртәбез. Белешмәләр – чатта. Алдынгы тәҗрибә – Интернеттан, түләүсез генә. Акча үзебезгә кирәк! Статистиканы «Excel» аша чыгарабыз! Нәрсәдер дөрес чыкмаса – соңгы таләпләргә туры китереп, юкка чыгарабыз. Ул чакта бөтен мәсьәләләрне хәл итәр өчен «Enter» төймәсенә бер басу җитә...

Ә безнең сөекле электоратыбыз юк-бар проблемалары белән теңкәгә тимәсен өчен, бөтен компьютерларга да "Фильтр" программасы урнаштырабыз. Һәрберебез һәм барчабыз аңлый торган версиясен, әлбәттә...

• • •

Нанотехнологияләр һәм кечкенә электрон җайланмалар гасырында кешеләр үзләре дә вакланып бетте.

• • •

Көн саен тугыздан алтыга кадәр, ай саен җидесе һәм егерме бере... Бу – яшәешебезнең «цифрага күчерелгән» асылы.

• • •

Без күчмә чорда яшибез. Полиция безне репостлар өчен тоткарлый ала, ләкин аларны аккаунтларга ыргытырга өйрәнеп җитмәде.

Виталия ПОДВИЦКИЙНЫҢ мини-вернисажы









ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

• Яхшы табиб авырудан коткара алмаса, һичьюгында начар табибтан коткарыр.

• Тук доктор – сәламәт авыру.

• Склерозны дәвалау мөмкин түгел, ләкин аның турында онытырга була.

• Бүген шулкадәрле дарулар барлыкка килде ки, организм яңа авырулар эшләп чыгарырга өлгерә алмый.

• Хастаханә – авырулар арасында тәҗрибә уртаклашу курслары ул.

• Ир гинекологка мөрәҗәгать итү – беркайчан да үз машинасы булмаган автомеханикка мөрәҗәгать итү кебек.

• Виртуаль тормыш белән артыгын мавыгу – реаль тормышта геморройга китерә.

• Кайбер авырулар даруга түгел, ә доктор колбасасына мохтаҗ.


• Әгәр табибка шәплəп түләсәң, авыруның хроник формага күчүе мөмкин.

• Кешенең сәламәтлеге өчен көрәштә статистика аеруча зур уңышларга ирешә.


Василий АЛЕКСАНДРОВ



Эльвира ДЫШАЕВА


Вячеслав ШИЛОВ



Сатира-юмор буенча кардәшебез **Камил КӘРИМОВка**... ничә яшь тулганын әйтеп тормыйбыз. Кыскасы, ул түгәрәк юбилеен билгеләп үтә. Кем генә булмаган ул – буровойда эшче дә, армиядә *солдат та*, культура институты студенты, режиссёр, сәхнә артисты, журналист, Язучылар берлегендә хезмәткәр дә... һәм кайда гына булса да, тормышта көлкеле әйберләр күреп, аларны кәгазьгә күчерә барган.

Озак еллар дустыбыз Камил "Чаян" журналында җаваплы сәркатип сыйфатында "юмор кырларында" тир түкте. Олы әдәбиятка бездән юл алды. Бүген ул дәрәҗәле әдәби журнал – "Казан утлары"нда хезмәт итә, романнар һәм пьесалар яза, дәүләт премияләре ала... Ә безнең өчен Камил Кәримов үзенең иҗаты белән чаянчыларның һәм журнал укучыларының күңелен яулаган шат күңелле, җор телле Шәле егете булып кала бирә...

ҮЗ ИТЕП КЕНӘ

- Үзең утырган ботакка балта чапма, пычкы белән кис.
- **Чиратың якынайган саен, дусларың арта.**
- Аерылыштык, аңа – кыз, миңа малай тиде. Сагынганда *алмаштырып сөябез.*
- **Ул шәм кебек төз иде, эреп төште.**
- Кияүгә чыгып керде.
- **Мәхәббәтнең күп өлеше оятсызлыктан тора.**
- Егет белән кыз чакта, йөрәк тә йөрәк, дибез, ә өйләнгәч, күбрәк ашказаны турында сөйләшәбез.
- **Мишәр кызлары белән танышсаң — азагы өйләндерү белән бетә.**
- Кешегә яраган гына ярамый, куян бүрек, сырган чалбар, бушлат белән киез итек кирәк аңа.
- **Безнең авылда ике яучы йөри: «кызын бирсен» дигәндә, Хәдичә китә, «бирмәсәләр ярар иде» дигәндә, Хәлимәне җибәрәләр.**

КӨН һәм ТӨН

Кояш та җирне тигез җылытмый...

Дөньябызның бер ягында – төн, икенче ягында – көн.

Яуропада таң атса, ерак Көнчыгышта кояш байый.

Урыс җирендә көн ачылса, Әмрикәдә көн бетә. Урыс малае йоклап ятканда, Әмрикәнең бәләкәче эшкә китә.

Мөселман кардәшләр, урыс дип атаганга кимсенмәгез, урыс сез пока – Мәскәү чиркәүләре чаң кагып уята, чаң сугып йоклата. Әгәр уятмаса, эшегезгә соңга калып, чукына-чукына, әстәгъфирулла, трамвай куар идегез, аңлатмалар яза-яза чукынышып бетәр идегез... Бездә шау-шулы көн туганда Әмрикәдә тып-тын төн уртасы, шуңа күрә алар чукына-чукына, әстәгъфирулла, тьфүтьфү, трамвайлар да куып йөрми, кабинетларда да чукынышмый.

Кояшы да аумакай бу дөньяның – ике арада тик йөри шунда буталып... Пентагонда таң атканда, Кремльдә караңгы төн. Капма- каршы тормыш! Алар ашый – без йоклыйбыз, без эшлибез, алар ашый. Без социализмга капиталь ремонт ясыйбыз, ә алар социализмнан капитал ясый. Без аларның империализмын сүгәбез, ә алар безнең коммунизмда яши.

Аларда хәтта сыра сөючеләрнең дә партиясе бар, ә без исә миллионер партиябезне дә сатып эчтек.

Түгәрәк Җир шарында торышларыбыз үзгә булган кебек, тормышларыбыз да үзгә. Бездә – төн, аларда – көн. Әмрикәнең джентльмены сөйгән кызы белән коктейль эчәргә килгәндә, сәвит мужигы инде сөяркәсе белән айныткычта төн кунып чыга. Мистерның олы кызы туй күлмәге кигәндә, товарищның кече кызы төзлеп кайтып та керә. Канзас-сити гимназисты сексопатологка сорау белән барганда, Казан пионеры гинекологка имтиханын алдырып кайта.

Бездә төн – аларда көн. Без йоклыйбыз, дошман йокламый. Колумбия мафиясе әле план гына кора, ә мәскәүнекеләр инде портфель бүлешә.


Аларда һәр кеше корал йөртә ди, байлыклары күптер... Получка алган көнне безне дә уклау күтәреп каршы алалар. Сәвит мужигына башка коралның кирәге юк.

Менә шулай, товарищ! Бездә төн – аларда көн. Аларда – инфляция, бездә – спекуляция, аларда – порнография, бездә – мафия, аларда – эшсезлек, бездә – бушсүзлек, бездә – демократия, аларда – демонстрация... Ә бер карасаң, бар да киресенчә. Чөнки көн белән төн алышынып тора. Аларда — көн, бездә – төн. Бездә – Кремль, аларда – Ак йорт. Бездә Горбачев, Ельцин, Шәймиев, аларда – Буш кына. Исеме Буш кына булса да, Әмрикәсе буш түгел.

Ярый ла Кояш Җирне тигез җылытмый... Әгәр мисал өчен, әйтик, кояш һәммәбезне дә тигез күрсә һәм бездә төн булганда аларда да төн булса, без йоклаганда йоклап, без уянганда гына уянсалар... Безгә кызыгып алар да революция ясаса?! Алар да безнең көнгә калачаклар. Перестройка дигәннәре аларның да күрмәгәнен күрсәтер!..









УКУ АВЫР

Пермьнең Новопетровка авылында яшәүче балалар дистанцион рәвештә эшләнгән биремнәрне укытучыга җибәрү өчен иске кәрәзле элемтә вышкасына менәргә мәҗбүр булганнар. Җирле укыту идарәсе, белә торып балаларны куркыныч астына куйган өчен ата-аналарны гаепләгән. Бөтен көчләр белән белем алырга теләүче укучыларны "риск группасы"на учетка куярга ниятлиләр. Ә бу проблемага зарланучы математика укытучысын дисциплинар җаваплылыкка тарту белән куркытканнар.

КЕЛӘМ УРЛАУ

ФСБ майоры Сергей Ренкас келәм урлауда эләккән. Материаль-техник бүлектә хезмәт итүче, дагстан эшмәкәренә ФСБның кабул итү бүлмәсен кулдан эшләнгән келәмнәр белән бизәргә тәкъдим иткән һәм үрнәкләр китерүен сораган. Сатучы 6,5 млн. сумга 9 келәм алып килгән, тик акчасын гына ала алмаган. Үпкәләгән эшмәкәр келәмнәрен эзләп табуын сорап, тикшерү комитетына мөрәҗәгать иткән.

ЙОРТСЫЗ-НИСЕЗ

Яшәү урыны булмаган мәскәүлене самоизоляция режимын бозган өчен штрафка тартканнар. Полицейскийлар аны Лианозовский парктан ерак түгел туктатканнар һәм өенә кайтуын сораганнар. Бомж яшәү урыны булмау турында әйткән. Тәртип саклаучылар аңа пропуск режимы вакытына фатирга керергә кушканнар, полиция бүлегенә китергәннәр һәм 4 мең сум штраф язганнар.

ЭКОЛОГИК ЭКСТРЕМИСТЛАР

Екатеринбургта экологик сугыш чыккан. Уралның дәүләт университеты территориясендә бассейн ясау өчен агачларны кискәннәр. "Яшел" активистлар бернинди дә бассейн булмаячагын ачыклап, ул урынга агачлар утыртканнар. Университетның мондый башбаштаклыкка ачулары чыккан һәм прокуратурага мөрәҗәгать иткәннәр. Шикаятькә "яшел"ләрне экологик экстремистлар дип атап, теләсә нинди җиргә агач утыртырга ярамый дип, шәһәрнең хакимияте дә кушылган.



МИРЗАҺИТ ТОРМЫШЫННАН

Гади авыл агае Мирзаһит турындагы хикәятләрне дәвам итәбез. Элеккечә фамилиясен атамыйбыз. Чөнки андый Мирзаһитлар һәрбер авылда да бар бит.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТЕВ

САКЧЫЛ ХУҖАБИКӘ

Мирзаһитның хатыны үтә сакчыл була. Хуҗалыкта бернәрсә дә әрәмгә китми. Хәтта әфлисун кабыгын да ул киптереп уа һәм һәм чәйгә, боткага, хәтта ашка да сала торган була.

Берзаман Мирзаһит колбаса алып кайта һәм елмаеп, хатынына әйтеп куя:

– Карале, карчык, колбаса кабыгын да әрәм булмасын өчен, берәр ничек уып файдаланып булмас иде микән?

ГАЛИ СПРАВКАСЫ

Элек авылда төп түләү чарасы булып аракы саналган. Бәрәңге басуын сөрдерергә кирәкме – «яртыңны» әзерлә. Утын кайтарырга – бер ярты. Эчмәгән кеше дә эш өчен барыбер аракы алган һәм аның белән башкаларга түләгән.

Ул чакта авыл кибетендә барысына Гали хуҗа булып торган, һәм аңа көне буе халык аракыга йөргән. Эш муеннан!

Мирзаһит ул вакытта пилорамада эшләгән. Берзаман кич белән аның янына шофёр Илгиз килеп кергән:

– Карале, күрше, әйдә, бүген бераз эшләп алыйк әле, миңа бүрәнәләр китерергә тиешләр. Өй салам бит.

– Маладис! Шәп эш бу, – дип җавап биргән аңа Мирзаһит. – Ә Галидән ысправка алып килдеңме соң?

Күршесе, елмаеп, куеныннан «документ» чыгарып куйган.

Шуннан бирле аракыны авылда «Гали справкасы» дип йөри башлаганнар...

БАР, ЭШЛӘ!

Эшкә табиблар килеп, сәламәтлекне тикшереп киткәннәр. Кичен барысы да җыелышып, шул турыда гәп сата башлаганнар.

– Минем холестерин югары, ашауны тәртипкә китерергә кирәк, – дигән Вәли.

– Ә миңа күзлек яздырдылар, күрү начарланган, – дип куйган Гөлгенә.

– Ябыгырга куштылар, – дип авыр сулап куйган Нияз, корсагын сыйпап.

Мирзаһитка чират җиткән.

– Нигә бер сүз дә әйтмисең, сиңа ни диделәр?

– Миңа «Бар, эшлә!» диделәр, – дип җавап биргән Мирзаһит.



Максим СМАГИН



Виктор ФЁДОРОВ



Юрий КУХАРЕНКО



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Нинди оятсызлык! Мин сиңа хатыным бала көтә дип хәбәр итәм, ә син "Кемнән?" дип сорыйсың.

– Гафу ит, дускай. Мин тулы мәгълүмат алырмын дип уйлаган идем.

• • •

Доктор янында:

– Сезгә киңәш кирәкме, әллә консультациями?

– Ә аермасы нәрсәдә?

– Киңәш – түләүсез, ә консультация – 500 сум.

– Алайса киңәш бирегез.

– Мин сезгә консультациягә язылырга киңәш итәр идем...

• • •

Вокзал ресторанында.

– Официант! Сез китергән итне инде ун минут буе чәйнәп чыгара алмыйм!

– Борчылмагыз! Сезнең поезд өч сәгатькә соңарып килә.

• • •

– Сайлауга кадәр депутатыбыз әллә ниләр вәгъдә иткән иде. Сайлану белән безнең турыда онытты.

– Табигый нәрсә. Синең кайчан да булса балыкны тотканнан соң аңа җим ашатучы балыкчыны күргәнең бармы?

• • •

Теш табибында.

– Сез тешне авырттырмыйча аласызмы?

– Кайчан ничек инде. Кичә, мәсәлән, берәү бармагын тешләде.

• • •

Сатып алучы үзен сүккән сатучыга ризасызлык белдерә.

– Хәзер үк әйткән сүзләрегезне кире алыгыз!

– Без бернәрсәне дә кире алмыйбыз. Алыштырып кына бирә алабыз.

• • •

– Буй-сыныңны ничек шулай зифа килеш саклый аласың?

– Майсыз затлы балык, киви һәм фейхоа гына ашыйм .

– Бу бит кыйммәт!

– Менә шуңа күрә дә саклый алам инде.

Юрий КУХАРЕНКО



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

• Барлык илләрдә дә тимер юл кешеләр һәм әйберләр йөртү өчен файдаланыла, ә бездә, өстәвенә, урлау өчен.

• Идарә итүнең сере – бернәрсәне дә тыймаска, бернәрсәне дә рөхсәт итмәскә.

• Әгәр барысы да дәүләт эшләре турында акыл сата башлаган икән – бу дәүләт беткән дигән сүз.

• Дөнья – гүзәл. Кешеләрдән башка тагын да гүзәлрәк.


• Медицина безне озаграк һәм газаплырак итеп үләргә мәҗбүр итә.

• Хөкүмәт ул – нәни бала кебек: бер башында тыелгысыз аппетит булса, икечесендә – тулы җавапсызлык.

• Әгәр бу дөньяда ахмакларны күрергә теләмисең икән, башта көзгеңне ватып ташла.

• Законнарны кабул итү өстендә йөзләгән кеше эшли, ә аларны ничек үтәмәү турында миллионнар баш вата.

(зыялылар акыл саткан чакта язып алынды)



Игорь КИЙКО



Гамил АФЗАЛ

ӘСМАБИКӘ ҖАНЫМ, АХИРӘТ

Якшәмбе көн нурлы иртәдә
Койма буйларында күләгә.
Әсмабикә килә урамнан,
Уң кулына тоткан чемодан.

– Әсмабикә җаным, ахирәт,
Безнең очта сиңа ни кирәк,
Бу чемодан нигә кулыңда?
Кызыл гөлләр сибим юлыңа!

– Малайкаем, чыктым кияүгә,
Сезнең очта торган берәүгә.
– Якты булсын, Әсма, уйларың,
Котлы булсын, җаным, туйларың!

Дүшәмбе көн нурлы иртәдә
Койма буйларында күләгә.
Әсмабикә бара урамнан,
Сул кулына тоткан чемодан.

– Әсмабикә җаным, ахирәт,
Аргы очта сиңа ни кирәк?
Бу чемодан нигә кулыңда?
Алсу гөлләр сибим юлыңа!

– Сезнең очтан кайтам берәүдән,
Уңмадым мин, дустым, кияүдән.
Кияү түгел – җирән алаша,
Минем белән көн дә талаша.

Сишәмбе көн нурлы иртәдә
Койма буйларында күләгә.
Әсмабикә бара урамнан,
Уң кулына тоткан чемодан.

– Әсмабикә җаным, күз нурым,
Кайсы якка тоттың бу юлың?
– Малайкаем, уңыш бу җәйдә,
Күрше авылга чыктым кияүгә.

Кияү түгел, егет солтаны,
Кичә кичен күрдем мин аны.
Егет түгел, пешкән җир җиләк,
Ак бәхетләр телә, ахирәт!

– Якты булсын, Әсма, уйларың,
Котлы булсын, җаным, туйларың!
Берәр атна инде бу җирдә
Килен булып тордың һәр өйдә.

Пәнҗешәмбе нурлы иртәдә
Читән буйларында күләгә.
Әсмабикә ындыр ягыннан
Кайтып килә күрше авылдан.

– Әсмабикә җаным, ахирәт,
Бу авылда сиңа ни кирәк?
– Малайкаем, күңелем шатлыгы,
Кияү түгел – адәм актыгы...

Ә анасы убыр, аждаһа,
Минем белән көн дә талаша,
Кайтам әле, алма кисәгем,
Бәдри Сәйфиендә исәбем.

• • •

Безнең якта чыкмый берәү дә
Атнасына алты кияүгә.
Гомер дусты, даими яр кирәк,
Әсмабикә җаным, ахирәт!

Виктор ИГНАТЬЕВ «Чаян» № 6, 1964



– Оятсыз да инде хәзер халык! «Чәйгә» дә бирмәде, ә үзе игътибар таләп итә...

Иван ХАНТИМИРОВ «Чаян» № 7, 1977



Алмаз ХӘМЗИН

СЕЗЛЕ-БЕЗЛЕ ДӨНЬЯ

Кызык дөнья...
Йә алдын, йә артын күрсәтә –
Алдында да, артында да
Без көтмәгән күп нәрсә...

Сукыр түгел...
Күрәбез дә кебек шикелле...
Күргәнеңне туры әйтү –
Безнең гадәт бит инде.

Ишетәбез...
Чукрак түгел, яшь бит әле без –
Телне кисеп торсалар да,
Үзебезчә сөйлибез.

Әле кызык...
Йөрәк әле тибә дөбердәп.
Диваналык бездә түгел.
Сездә бит ул күберәк!





Александр БРЮХАНОВ

МӘҢГЕЛЕК СОРАУЛАР

– Кухняда краннан тама, – дип кычкырды хатын һәм ирнең башында шундук мәңгелек сораулар калкып чыга башлады.

Кем гаепле? Хатын артыгын борып җибәргәнме? Әллә күрше кереп, белдеклеләнеп бозып чыкканмы?...

Җавап юк...

Нишләргә? Бәлки, берәр ничек үзе рәтләнер әле... Бәлки, сантехник чакыртыргадыр... Әллә диваннан торып, үземә маташтырып карагадыр...

Дөрес җавап табу катлаулы шул... Үзең тотынсаң – яңа прокладкалар, бәлки, яңа кран куярга кирәктер... Ә акча кайда? Заводтагы хезмәт хакы очын очка ялгарга гына җитә. Кем гаепле? Мин гаепле түгел. Бәлки, нәчәлстводыр – килешенүләрне вакытында төземәгәннәр... Берни дә аңлашылмый...

Нәрсә эшләргә соң? Бәлки, соңгы акчаны алып кибеткә барып кайтыргадыр? Ә ул ябык булса? Монысына кем гаепле?.. Хәзер бөтен нәрсә дә ябыла бит...

Ә кем гаепле? Бәлки, шәхси мәсьәләләрне хәл итәргә бирмәүче нәчәлстводыр... Әллә өстә берәрсеме?.. Юк, болай әллә ниләр әйтеп ташларга мөмкин... Иң мөһиме: кем гаепле булуда түгелдер...

Эчүне ташлап чаңгыда йөри башласам?.. Әй, җәен ниди чаңгы булсын... Гер күтәрергә – радикулит... Бәлки, барысына да төкерергәдер...? Төкереп кара – хатын идән юдыртачак...

Катлаулы сораулар, яхшылап уйламыйча булмый...

– Ишетәсеңме, кран тама дим, ә син дөнья мәсьәләләрен хәл итеп утырасың...

– Нишләргә икәнен аңларга телим.

– Нишләргә? Кулыңа ачкыч ал да рәтлә кранны...



СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛЛАР

Хөрмәтле редакция! Республика шәһәрләрендә барлыкка килгән велосипед юлларын халык тиз арада яратып өлгерде. Түбән Кама да читтә калмады, әлбәттә. Ләкин бу юлларның саны артса да, сыйфаты начарлана бара.

Мисал өчен, Тынычлык проспектында брустан эшләнгән юл озак хезмәт итә алмады. Бигрәк тә кыштан соң, педаль әйләндерергә яратучыларны куңелсезлекләр көтә иде. Әлеге юлда куркыныч велосипед тәгәрмәчләренә генә янамый, үзенә дә сизелерлек зыян салуыңны көт тә тор.

Бу куңелсезлекләр һава температурасының кискен алышынуы нәтиҗәсе икәнен мәктәп укучысы да беләдер. Кызганыч, юлларны 31 августка гына төзәтә башлаячаклар, ә анда инде көз җитте дигән сүз, салкын сезонга да ерак түгел...

Ә. ШАКИРОВ

ТҮБӘН КАМА

ЧҮПЛЕККӘ ТӨБӘЛГӘН ЙОРТЛАР

Кадерле «Чаян»! Без йортыбызның әйләнә-тирәсен матурлап, ямьләндереп, яшелләндерүне зур түземсезлек белән көттек. Бигрәк тә йортлар арасында, күз явын алырдай чыршылар утыртылган сылу аллея пәйда буласы иде бит. Әмма кырыс тормыш татлы хыялларыбызны чәлпәрәмә китерде – яшеллек буласы урынга чүп контейнерлары өчен мәйданчык төзи башладылар.

Безнең мөрәҗәгатьләр игътибарсыз калды. Проект буенча, чүп контейнерлары, янәшә торган йортлардан 20 метр читкәрәк урнашырга тиеш икән. Ә арткы йорт мәйданчыгы бу таләпләргә тулысынча туры килә, теләсәң, чүп яндыру заводы ачып җибәрергә дә була. Ләкин кемнеңдер фикере буенча, тәрәзә каршындагы манзара чыршыларга караганда, җанга ятышлырак, күрәсең...

Камалиев урамындагы 30, 32 нче санлы йорт хуҗалары

КАЗАН



Илдар НӘФИЕВ



ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР

Язылган өчен мотоблок, ТВ, планшет һәм башка бүләкләр от!

Бүләкләр 2020 елның 19 августында уйнатылачак



1 язып — 2020 елның 30 июнена кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең газета һәм журналына язып (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең күчермәсен безгә җибәр (телефон номерын язарга онытма). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от — Язылган өчен мотоблок, телевизор, планшет, тузансуырткыч, 100 л бензин, блендер, үтүк от



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибен tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2020 елның 12 маеннан 2020 елның 20 сентябренә кадәр үткәрелә. Гаризалар 2020 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+ Бүләкләр рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.



Илебез — нәкъ гөлбакча...

ДАЧА ХИКМӘТЛӘРЕ

• Бу көзнең төп проблемасы – кем өчен тавыш бирү түгел, ә каһәр суккан ташкабакларны кая кую мәсьәләсе булачак.

• Авылда үз өең булу шәп инде. Иртән бакчаңа йөгереп чыгасың, ә кичен үрмәләп керәсең...

• Дача ул – икенче никах вазыйфасы, ә алтмыштан соң – беренчесе.

• Бәрәңге казыганда артыңа борылып карама – югыйсә калган эшеңнең күләме сиңа мәңгелек булып тоелачак.

• Байларның дачалары да аерым тора.

• Бакча – тылсымлы нәрсә. Бәрәңге утыртасың, борчак казып аласың.

• Уңышлы сатылган дача – анда үстерергә мөмкин булганнан күбрәк яшелчә һәм җиләк-җимеш бирә.

• Алты сутыйда әлсерәп ял итүдән дә рәхәт нәрсә юк.



Валерий ТАРАСЕНКО



Ринат АБЗАЛОВ



Олег ГУЦОЛ





Безнең "Оптимист" дигән бакчачылык ширкәтендә Иван исемле бер архитекторның да дачасы бар иде. Аның "өй" дигән корылмасы түбәдән генә тора иде кебек. Чөнки ян-як стеналарының биеклеге метр ярым чамасы гына итеп алынган. Кыш көне ул да кар белән капланып, чана шуарлык тауга ошап кала иде. Узган-барган бакчачылар аңа сокланып карап кына калмыйлар, кайберләре хәтта хуҗасының рөхсәте белән өй эченә дә күз салып чыгарга тырышалар иде. Кулыннан эш килә торган бик уңган егет иде, иҗат кешесе иде ул. Болар өстенә күп ир-атларга хас бер сәер гадәте дә бар иде. Үзе белән ала килгән "кучтәнәч"е җитми кала иде. Мин мәктәп системасында эшләгәнлектән, җәйге каникул елларым шул бакчада уза. Шуңа да аның юлына мин ешрак юлыкканмындыр, мөгаен.

– Ни бит, яшьти, җитми калды. Акча биреп тора алмассыңмы? Кибет ябылганчы барып килергә иде, – ди.

Белгән кеше булгач, каршы килә алмыйм.

– Акча юк, ярты бар, тирес китерергә сөйләшкән идек. Шушы шешәне биреп торам. Үзем булмасам, өй нигезендәге шушы почмакка куеп китәрсең, – дим. Ул бик теләп риза була.

Ул вакытта юклык заман. Узган гасырның туксанынчы еллары. Бакча тирәсе дә киртә белән генә әйләндереп алынган. Теләгән кеше бакчаны үтә чыга ала дигәндәй. Шулай да мин киртә тирәсендәге казылган җирне тырма белән тырмалап китә идем. Чит кеше керә-нитә калса, белер өчен дип. Бервакыт карыйм, мин тырмалап киткән җирдә ят эзләр бар, теге "почмак"ка таба юнәлгән. Иван кергәндер дип уйлыйм. Барып карарга җай чыкмады бугай. Бер-ике көннән үзе дә очрады.

– Мин сез күрсәткән урынга куйдым, – ди.

Дөресен генә әйткәндә, ул вакытта миңа аның кирәге дә булмады, тиресне китерә алмадылар, ә Иван мин югында бер алып, бер куеп йөрде бугай, чөнки теге эзләр күренгәләп алгалый иде.

Урман аркылы тимер юл станциясенә кайтканда бергә сөйләшеп кайтырга да туры килгәләде аның белән. Сүз ара сүз чыккач, мин Иванның филателист икәнлеген дә белдем. Маркалардан тыш, төрле елларда чыккан аракы-шәраб ише алкогольле эчемлекләрне дә аерым бер коллекция итеп җыеп бара икән. Монысына ышанмадым.

– Ничек инде? – дип сорап куйдым.

– Шулай. Әтидән калган гадәт. Аларга кагылырга кул бармый...

Узган җәй бакчада кичке якта күршеләр белән сөйләшеп утырабыз. Сүз көндәлек эшләр турында бара. Дөнья хәлләренә кереп кителә. Танышбелешләр искә алына.

– Күптән инде Иванны күргәнем юк, – дим.

– Ул исән түгел бит. Биш-алты ел бардыр инде, – дигән җавап ишетәм. Ничектер, күңелгә моңсу булып китте... һәм теге вакыйгага искә төште. Болай гына, кызык өчен генә кайтып килергә булдым. Кулымны нигездәге почмакка тыгып карасам, бармакларга каты әйбер бәрелде. "Сельская жизнь» газетасына уралган бер шешә тартып чыгардым...

Бик матур бизәк төшереп ясалган яшел төстәге этикеткага аерым-аерым юлларга "Водка Московская Особая" диелгән. Астарак бәясе, елы күрсәтелгән: "2 руб. 87 коп. 1967". Бу аракының ясалганына да ярты гасыр түгелме соң, дип гаҗәпләндек без. Ул барыбызга да бик таныш иде, шуңадырмы кулдан-кулга күчеп йөрде. Һәммәбез дә аны тоткалап, әйләндергәләп, һәр хәрефен диярлек игътибар күзлегеннән уздырып чыктык. Ул әллә нинди хатирәләрне искә төшерде, чөнки дөньясы шуның белән бара иде. Хуҗалыктагы теләсә нинди эшне: әйтик, ат белән бәрәңге утырту, басудан салам китертү, бәрәңге бакчасын трактор белән сөрдерү һәм башкаларны шушы бер "ярты"га эшләтеп була иде...

Яшел этикеткалы әлеге шешәне "бушатып" Иванны искә алгач, ярты төнгә чаклы шуңа охшаш хатирәләрне яңартып утырдык.

Мидхәт САДЫЙКОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 6 (1895) июнь 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 2.06.2020 ел.
Тираж – 1208 Заказ А-1110

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+





Вожык

Часопіс сатыры і гумару

СССРда сатира-юмор журналлары җитәрлек иде. Ләкин заманалар үзгәреп куйды, һәм аларның күбесе юкка чыкты. Хәтта легендага әверелгән "Крокодил" да шул хәлгә дучар булды. Майдан учакларында Украинадагы "Перец", янып, күккә очты, Балтыйк буе илендә чыга торган "Шлуота" һәм "Пиккер" күренми башлады, Урта Азиядәге "Муштум" һәм "Чалкан" турында күптәннән берни ишетелгәне юк...

Ә менә совет традицияләренең төп саклаучысы булган Белоруссиядә, укучыларын үткен шаяртулар һәм көн кадагындагы карикатуралар белән шатландырып, әлегәчә "Вожык" журналы чыгып килә. Минск "керпе"се даими рәвештә үз битләрендә элекке Союз мәйданында сакланып калган көлке журналлары рәссамнарының сәхифәләрен бастыра. Анда "Чаян"га да кунакта булырга насыйп булды. Ә хәзер безнең чират җитте – укучыларыбызны белорус юморының иң гүзәл үрнәкләре белән таныштырырга булдык...











В. Чуглазов, В. Пузанкевич һәм А. Каршакевич рәсемнәре.


4 612750 670080